| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«МУКМИН-КАРАТАЙСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«МӨЭМИН-КАРАТАЙ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

**№20**

**2018 елның 02 июле**

**Лениногорск муниципаль районы «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2015 елның 20 ноябрендәге 22 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 маддәсенең 19 пункты нигезендә, норматив-хокукый актны Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нормаларына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы, «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы Уставы нигезендә КАРАР БИРДЕ:

1.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) түбәндәге эчтәлекле 209.1 пункт өстәргә:

«201.1 яшелләндерелгән территорияләрдә, балалар һәм спорт мәйданчыкларында, хайваннарны йөртү мәйданчыкларында, шулай ук йорт яны территориясендә урнашкан хуҗалык мәйданчыкларында транспорт чарасы урнаштыру тыела.

1) яшелләндерелгән территория - гомуми файдалану территориясе, табигый чыгышлы үсемлекләр урнашкан җир участоклары, ясалма төзелгән бакча-парк комплекслары һәм объектлары, бульварлар, скверлар, газоннар, чәчәкләр, аз төзелгән торак, иҗтимагый, эшлекле, коммуналь, җитештерү билгеләнешендәге территория, аның чикләрендә өслекнең кимендә 70 проценты үсемлекләр капламы биләгән;

2) балалар һәм спорт мәйданчыклары - балалар спорт мәйданчыгын җиһазлау һәм каплауны үз эченә алган аңлы хәрәкәт активлыгы процессында балаларның психофизик сәләтләрен үстерү өчен билгеләнгән махсус җиһазландырылган территория. Периметр буенча киртә (бордюр) булмаганда, транспорт чарасын уен-спорт комплексына (комлык, таулык, балансир, турник һәм башка кече архитектура формаларына кадәр биш метр ераклыкта урнаштыру тыела).

3) хуҗалык мәйданчыклары - электр көч приборлары урнаштыру мәйданчыгы, контейнер мәйданчыгы, кер юу мәйданчыгы, территориягә хезмәт күрсәтү, эксплуатацияләү һәм төзекләндерү өчен билгеләнгән башка объектлар. Мәйданчыкны чикләүче (бордюр) булмаганда, периметр буенча киртәләр, хуҗалык мәйданчыгына кадәр өч метр ераклыкта транспорт чарасын урнаштыру тыела.

4) хайваннарны йөртү өчен мәйданчыклар - җирле үзидарә органының норматив-хокукый акты белән билгеләнә торган хайваннарны йөртү өчен махсус бүлеп бирелгән урыннар.».

2. Әлеге карарны Мөэмин-Каратай выл җирлеге буенча урнашкан мәгълүмати стендларда игълан итәргә һәм әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Мөэмин-Каратай авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Ә.А.Ханнанова